ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21. 11. 2025 Олы Кайбыч ав. № 518

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 406 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау һәм 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча бер укучыга түләүсез кайнар ризыкның уртача бәясе турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 726 номерлы, «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны тукландыруны тәэмин итү хакының нормативларын раслау турында» 2025 елның 03 октябрендәге 787 номерлы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2024 елның 08 ноябрендәге 406 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Кайбыч муниципаль районы бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучыларны 2026 елда – 77,76 сум, 2027 елда - 80,87сум, 2028 елда 84,1 сумлык түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә»;

1.2. 2.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Кайбыч муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны көнгә бер укучы балага 2026 елга 10,7 сум, 2027 елга 11,1 сум, 2027 елга 11,5 сум күләмендә субсидиядән һәм ата-ана (законлы вәкил) түләвеннән торучы ризык белән тәэмин итәргә».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров